ГЛАВА БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«22» 06 2018 ел № 102

«Коррупция: коррупцияне профилактикалау һәм аңа каршы тору буенча журналист карашы» конкурсын оештыру турында

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында коррупциягә каршы көрәш буенча эшне координацияләү комиссиясенең 2018 елның 12 апрелендәге 1 номерлы беркетмәсен үтәү йөзеннән һәм массакүләм мәгълүмат чараларының һәм җәмәгатьчелекнең игътибарын районда коррупция проблемаларына җәлеп итү максатларында Балтач муниципаль районы башлыгы карар бирә:

1. 2018 елның 1 июленнән 30 октябренә кадәр район территориясендә «Коррупция: коррупцияне профилактикалау һәм аңа каршы тору буенча журналист карашы» конкурсын оештырырга һәм үткәрергә.

2. «Коррупция: коррупцияне профилактикалау һәм аңа каршы тору буенча журналист карашы» район конкурсы турында нигезләмәне 1 нче кушымта нигезендә расларга.

3. «Коррупция: коррупцияне профилактикалау һәм аңа каршы тору буенча журналист карашы» район конкурсының конкурсының жюри составын 2 нче кушымта нигезендә расларга.

4. Үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Респуликасы Балтач муниципаль районы башлыгы урынбасары Н.Н.Сабирҗановка йөкләргә.

Балтач муниципаль район
башлыгы Р.Р.Нотфуллин